Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Азево авыл җирлегенең Ташлы торак пунктында **ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2019 ел, 19 октябрь № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Азево авыл җирлеге Ташлы торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ:**

1. I группа инвалидлар, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия армиясендә хезмәт итүче затлардан тыш, Азево авыл җирлеге Ташлы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, үзара салым акчасын 2020 елда 300 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирлектә әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

-Ташлы авылы урамнарын кардан чистарту.

-Ташлы авылының Үзәк һәм Нагорная урамнарын тоташтыручы күперне ремонтлау.

3. Гражданнарның җыен нәтиҗәләрен Азево авыл җирлеге мәгълүмати стендларында урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
муниципаль берәмлек Башлыгы, Совет Рәисе В.С. СЕМЕНОВ